ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

15.09.2022 — с. Верхний Услон — 1001

«Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

«Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 04.02.2021 ел, №68 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә эшләнгән муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән хисап чоры өчен «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча нәтиҗәле эш максатларында, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикаларын һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеген раслау турында» 03.04.2021 ел, № 542 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17.07.2019 № 915 карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» карары белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 31.12.2009 ел, № 920 карары белән расланган һәм «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән күрсәткечләр җыю тәртибен билгели торган Татарстан Республикасы электрон документ әйләнеше ведомствоара бердәм системасының «Контроль» модуле эшчәнлеге тәртибе нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Гармонияле үсеш һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау

механизмы буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын (1 нче кушымта) расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе И.И Шакиров

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет Җитәкчесенең
_____________2022 ел №___
карарына

1 кушымта

«Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

Җирле үзидарә органы эшчәнлегенең әлеге Регламенты «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 04.02.2021 ел, №68 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә эшләнгән муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән хисап чоры өчен «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча нәтиҗәле эш максатларында, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикаларын һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеген раслау турында» 03.04.2021 ел, № 542 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17.07.2019 № 915 карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» карары белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 31.12.2009 ел, № 920 карары белән расланган һәм «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән күрсәткечләр җыю тәртибен билгели торган Татарстан Республикасы электрон документ әйләнеше ведомствоара бердәм системасының «Контроль» модуле эшчәнлеге тәртибе нигезендә эшләнгән (алга таба - Күрсәткеч).

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы өчен җаваплылык үзәге булып, тиешле вәкаләтләргә ия булган «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе тора (алга таба – Җаваплылык үзәге).

Кирәкле мәгълүматларны җыючылар булып дәүләт, муниципаль һәм башка оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка инициаторлар тора (алга таба - Мәгълүмат җиткерүчеләр).

## II. Төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр

Тәрбия-ул шәхесне үстерүгә, социаль-мәдәни, рухи-әхлакый кыйммәтләр һәм Россия җәмгыятендә кабул ителгән кеше, гаилә, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә тәртип нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә укучыларны үзбилгеләндерү һәм

социальләштерү өчен шартлар тудыруга, укучыларда Ватанны саклаучылар истәлегенә һәм Ватан геройлары батырлыгына хөрмәт, закон һәм хокук тәртибе, хезмәт кешесенә һәм өлкән буынга үзара хөрмәт, Россия Федерациясенең күпмилләтле халкының мәдәни мирасына һәм гореф-гадәтләренә, табигатькә һәм әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлтелгән эшчәнлек.

Гражданлык тиңдәшлеге - гражданнарның аңында аларның үз дәүләтләренә, халкына, җәмгыятькә, гореф-гадәтләренә, ил язмышы өчен җаваплылыгына, гражданлык хокукларын һәм бурычларын үтәү зарурлыгына каравын формалаштыру, шулай ук рухи-әхлакый кыйммәтләр, социаль теләктәшлек, сәнгать, тел һәм дөньяга карашның үзенчәлекләрен чагылдыра торган Россия җәмгыятенең база кыйммәтләренә бирелгәнлеге.

«Мәктәп укучылары өчен мәдәният» ведомствоара проекты - Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының мәдәни-мәгариф проекты.

## III. Күрсәткеч исәбе стандарты

«Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләп чыгару өчен, түбәндәге декомпозицияләнгән ярдәмче күрсәткечләр куллныла:

1. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән яшь авторлар һәм башкаручылар тарафыннан грантлар һәм стипендияләр алу өчен юнәлдерелгән заявкалар саны,берәмлек;
2. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән проектларны гамәлгә ашыру өчен, шул исәптән Россия халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән коммерциягә карамаган оешмаларга грант ярдәме кысаларында, җибәрелгән заявкалар саны, берәмлек;
3. Квалификация күтәрүне узган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре саны, кеше;
4. «Мәктәп укучылары өчен мәдәният» ведомствоара проектында катнашучылар саны, берәмлек;
5. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында, шул исәптән «Җиңү юллары»нда катнашучылар саны, берәмлек;
6. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Россия халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлтелгән коммерциягә карамаган оешмалар чараларына килүчеләр саны, берәмлек;
7. «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны», берәмлек.

## IV. Мәгълүмат җыю тәртибе, сроклары һәм формалары

Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрдән җаваплылык үзәгенә күрсәткечне исәпләү өчен кирәкле ярдәмче күрсәткечләр әһәмияте турында мәгълүмат бирү рәвешләре Регламентка 1-7 нче кушымталарга туры килергә тиеш. Тутырыла һәм Татарстан Республикасы Мәдәният Министрлыгының проект офисына (алга таба – Министрлыкка) җибәрелә торган күрсәткечнең әһәмияте турында җыелма форма –

«Таткультресурсурсцентр» ДБУ җаваплылык үзәге хезмәткәре тарафыннан Регламентка 8 нче кушымтада тәкъдим ителгән.

Мәгълүмат җиткерүчеләр тарафыннан Җаваплылык үзәгенә электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта, оешма җитәкчесе кул куйган һәм мөһер беркетелгән мәгълүмат тапшырыла.

Кәгазьдә кергән һәм электрон рәвештәге мәгълүмат җаваплылык үзәге билгеләгән форматтагы мәгълүматлар базасына кертелә (Microsoft Excel, Microsoft Access һ.б.). Шул ук вакытта кәгазьдә кергән мәгълүмат әлеге вәкаләтләр беркетелгән җаваплылык үзәге хезмәткәре тарафыннан таблицага күчерелә. Агрегацияләнгән мәгълүмат Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгълүмат җиткерүчеләр мәгълүматына нигезләнеп төзелә һәм Министрлыкның «Таткультресурсцентр» ДБУнең проект офисына, хисап чорыннан соң электрон документлар әйләнеше системасыннан файдаланып килүче айның 5 числосына кадәр, җаваплылык үзәге тарафыннан тапшырыла һәм муниципаль электрон исәп-хисап журналында 5 ел дәвамында саклана. «Таткультресурсцентр» ДБУнең Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнары буенча үз мәгълүматларын алга таба электрон документлар әйләнеше системасын кулланып, хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр Министрлыкка тапшыра. Министрлык адресына тапшырыла торган мәгълүматның (белешмәләрнең) эчтәлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары нигезендә билгеләнә.

1 кушымта

«Яшь авторлар һәм башкаручылар тарафыннан Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән грантлар һәм стипендияләр алу өчен җибәрелгән гаризалар саны» күрсәткече буенча хисап мәгълүматлары
(мәгълүматны җиткерүчеләр тарафыннан тутыру өчен)

| т/б № | Заявкалар җибәрү инициаторы | Дата | Грантлар һәм стипендияләр алу өчен җибәрелгән заявкалар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

2 кушымта

«Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыру өчен җибәрелгән гаризалар саны, шул исәптән коммерциячел булмаган оешмаларга грант ярдәме кысаларында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча күрсәткеч буенча хисап мәгълүматлары
(мәгълүматны җиткерүчеләр тарафыннан тутыру өчен)

| т/б № | Заявкалар җибәрү инициаторы | Дата | Проектларны гамәлгә ашыру өчен җибәрелгән заявкалар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

3 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча «Квалификация күтәрүне узган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре саны» күрсәткечләре буенча хисап мәгълүматлары
(мәгълүматны җиткерүчеләр тарафыннан тутыру өчен)

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Дата | Квалификация күтәрүне узган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

4 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча «Мәктәп укучылары өчен мәдәният» ведомствоара проектында катнашучылар саны» күрсәткече буенча хисап мәгълүматлары
(мәгълүматны җиткерүчеләр тарафыннан тутыру өчен)

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Дата | Проектта катнашучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

5 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә гражданлык тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларга килүчеләр саны» күрсәткече буенча хисап мәгълүматлары
(мәгълүматны җиткерүчеләр тарафыннан тутыру өчен)

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Чараның атамасы | Дата | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

6 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән» мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар саны» күрсәткечләре буенча хисап мәгълүматлары
(мәгълүматны җиткерүчеләр тарафыннан тутыру өчен)

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Программаның исеме | Дата | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

7 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны» күрсәткече буенча хисап мәгълүматлары
(мәгълүматны җиткерүчеләр тарафыннан тутыру өчен)

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Чараның атамасы | Дата | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

8 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткече буенча мәгълүматларны мониторинглау формасы
(җаваплылык үзәге тарафыннан тутыру өчен)

| т/б № | Ярдәмче күрсәткечнең атамасы | Ярдәмче күрсәткечнең планы*. | Ярдәмче күрсәткечнең фактик әһәмияте | Планлы күрсәткечтән читкә тайпылу сәбәпләре** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән яшь авторлар һәм башкаручылар тарафыннан грантлар һәм стипендияләр алу өчен җибәрелгән гаризалар саны, берәмлек | | | |
| 2 | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән проектларны гамәлгә ашыру өчен җибәрелгән, шул исәптән Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән коммерциячел булмаган оешмаларга грант ярдәме кысаларында да, | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гаризалар саны | | | |
| 3 | Квалификация күтәрүне узган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре саны, кеше | | | |
| 4 | «Мәктәп укучылары өчен мәдәният» ведомствоара проектында катнашучылар саны, берәмлек | | | |
| 5 | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә тәңгәллекне ныгытуга юнәлдерелгән чараларга килүчеләр саны, берәмлек | | | |
| 6 | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән укучылар өчен мәдәни-агарту программаларында, шул исәптән «Җиңү юллары»нда катнашучылар саны, берәмлек | | | |
| 7 | Татарстан Республикасы бюджеты, берәмлекләре исәбеннән гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны | | | |

* - 3 графасы Татарстан Республикасы муниципаль районнары өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан формалаштырыла

* * - 5 графасы план күрсәткечләрен үтәмәгәндә җаваплылык үзәге тарафыннан тутырыла